РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

**СОВЕТ ЧИСТОПОЛЬСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

**ЧИСТАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ СОВЕТЫ**

---

***Решение*** ***Карар***

**10 март 2023 ел** **Чистай шәһәре** **№ 21/2**

Татарстан Республикасы
Чистай муниципаль районы Советының
«Татарстан Республикасы
Чистай муниципаль районында
муниципаль хезмәт турында»гы
2019 елның 23 маендагы 44/3 номерлы
карарына үзгәрешләр кертү хакында

«Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү һәм Россия Федерациясе закон актларының аерым нигезләмәләренең үз көчләрен югалтуын тану турында»гы 2022 елның 28 декабрендәге 569-ФЗ номерлы, «Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында»гы 2022 елның 5 декабрендәге 498-ФЗ номерлы федераль законнар, «Муниципаль хезмәт турындагы Татарстан Республикасы кодексының 42 статьясына үзгәреш кертү хакында» 2021 елның 27 декабрендәге 97-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә, Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы Советы

**КАРАР БИРӘ:**

1. Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы Советының «Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районында муниципаль хезмәт турында»гы 2019 елның 23 маендагы 44/3 номерлы карары белән расланган Чистай муниципаль районында муниципаль хезмәт турындагы Нигезләмәгә (Чистай муниципаль районы Советының 2019 елның 26 сентябрендәге 47/3 номерлы, 2020 елның 20 гыйнварындагы 52/2 номерлы, 2020 елның 15 декабрендәге 3/7 номерлы, 2021 елның 11 августындагы 9/3 номерлы карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 4 статьяның 7 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«7. «Татарстан Республикасында тәртип саклау буенча җәмәгать пунктлары турында» 2015 елның 25 апрелендәге 33-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә, муниципаль хезмәтнең тиешле вазыйфасы буенча вазыйфаи бурычларына җәмәгать тәртибен тәэмин итүдә катнашу кергән очракта, 2025

елның 1 гыйнварына кадәр муниципаль хезмәт вазыйфаларының өлкән һәм кече төркемнәре вазыйфаларын биләү өчен һөнәри белем дәрәҗәсенә карата квалификация таләпләре куелмый (урта гомуми белем булган очракта).»;

1.2. 11 статьяның 1 пунктына түбәндәге эчтәлекле 12 пунктча өстәргә:

«12) аның чит ил агенты статусын алуы.»;

1.3. 20 статьяның 2 пунктындагы 4 пунктчасында «Россия Федерациясе Пенсия фонды» сүзләрен «Россия Федерациясе пенсия һәм социаль иминләштерү фонды» сүзләренә алмаштырырга.

2. Чистай муниципаль районы Советының оештыру бүлегенә әлеге карарны билгеләнгән тәртиптә бастырып чыгарырга, шулай ук Чистай муниципаль районының «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә рәсми сайтында урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Чистай муниципаль районы Советының Законлылык, хокук тәртибе һәм депутат эшчәнлеге мәсьәләләре буенча даими депутат комиссиясенә йөкләргә.

Чистай муниципаль
районы Башлыгы Д.А. Иванов